**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2092**
**24.03.2023**

Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында» 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 номерлы карары (Башкарма комитетның 2014 елның 17 февралендәге 944 номерлы, 2015 елның 18 ноябрендәге 6571 номерлы, 2016 елның 29 апрелендәге 2159 номерлы, 2017 елның 6 апрелендәге 1955 номерлы, 2018 елның 7 мартындагы 1180 номерлы, 2019 елның 22 октябрендәге 5404 номерлы, 2021 елның 10 февралендәге 886 номерлы, 2023 елның 16 февралендәге 1020 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның беренче һәм икенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Компенсация алу хокукын билгеләгәндә, гаиләнең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында» 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы Карары белән билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләнә.

Компенсация билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме компенсация билгеләү турында гариза бирә торган айга кадәрге ай алдыннан

килүче соңгы 12 календарь ай (алга таба – хисап чоры) өчен гаилә әгъзаларының керем суммасыннан чыгып билгеләнә.»;

2) 10.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.1 Компенсация билгеләү, гаризада күрсәтелгән гариза бирүченең ризалыгы буенча, компенсация билгеләү турында гариза бирә торган айга кадәрге ай алдыннан килүче соңгы 12 календарь ай өчен салым органыннан алынган мәгълүматлар нигезендә башкарыла.»;

3) 14.1 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

4) 7 пунктның 3 пунктчасында «дәүләт хезмәтеннән файдаланучы тарафыннан алынган өстәмә компенсация бирү турында гариза тапшыру аеннан алдагы алты ай өчен» сүзләрен «компенсация билгеләү турында гариза бирә торган айга кадәрге ай алдыннан килүче соңгы 12 календарь ай өчен» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов